КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 5 сентябрь г.Казань № 1074

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 937 нче карары белән расланган Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 937 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 февраль, 167 нче, 2022 ел, 24 октябрь, 1135 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә, 17.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«17.1. Планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасы төрен үткәрү һәм сайлау турында карар кабул иткәндә зыян (зарар) китерү куркынычын бәяләү максатларында Министрлык тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары билгеләнә:

милкендә, оператив идарәсендә яисә файдалануда музей әйберләре һәм музей тупланмалары булган, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы

карамагындагы дәүләт музее саклагычларында саклау сигнализациясенең календарь ай дәвамында өч тапкыр ялган эшләве факты;

узган календарь ел белән чагыштырганда «Музей эшчәнлеге турында мәгълүматлар» 8-НК номерлы федераль статистик күзәтү формасы мәгълүматлары буенча календарь ел ахырына реставрация таләп итә торган төп фонд предметлары өлеше үзгәрү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин